БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №12 (7029) | 30 январь. 1990 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

## Бишнең берсе—иң яхшысы

Норлат-Октябрь автотранспорт предприятиесендә бригадалар бишәү. Алар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән. Узган ел нәтиҗәләре буенча Владимир Петрович Логинов җитәкчелегендәгесенә тиңнәр булмады. Нефтьчеләргә хезмәт күрсәтүче бу коллектив үзенә җиткерелгән планнарны 119,1 процентка үтәде.

Шундый уңганнарның бердәм тырышлыгы нәтиҗәсендә, тулаем предприятие буенча да еллык планнар уңышлы үтәлде. Шушы чорда, мәсәлән, пландагы 288 мең тонна урынына 303,4 мең тонна халык хуҗалыгы йөкләре күчерелде. Пассажирлар күчерү планы да арттырып үтәлде.

## Мәрхәмәтлек

Шәфкать, шәфкатьлелек. Соңгы вакытларда мондый сүзләр еш яңгырый башлады.

Телевидениенең икенче программасы гомумсоюз программасы буенча В. И. Ленин исемендәге совет балалар фондына ярдәм йөзеннән 24 сәгатьлек телемарафон булган иде. Әлеге акция әнә шушы мәрхәмәтлек, шәфкатьлекне тагын бер кат раслады. Шушы кыска гына вакыт эчендә балалар фондына 60 миллионнан артык акча кертелде.

Бу гуманлык акциясеннән безнең район халкы да читтә калмады. Норлат-Октябрь ит комбинаты эшчеләре, инженер-техник работниклары Чистай балалар йортына ярдәм йөзеннән 1.100 сум күләмендә бер көнлек хезмәт хакларын күчерделәр.

## Махсус счетка —3 мең сум

Казан моторлар төзү производство берләшмәсе коллективы мөрәҗәгатенә районыбызның күп кенә коллективлары кушылды.

Күптән түгел Норлат-Октябрь ит комбинаты коллективы район эчке эшләр бүлеге счетына 3 мең сум акча күчерде.

Комбинат эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре районның башка оешмалары, предприятиеләре коллективларын алар үрнәгенә ияреpгә чакыра. «Милициягә ярдәм тыныч тормышыбызны тәэмин итүгә өлеш булыр», диләр ит комбинаты хезмәткәрләре.

И. ЕРЕПОВ.



Рәсемдәге егетнең йөзенә игътибар итегез. Шатлыктан балкый ул. Ә болай итеп тормышта үз юлын, бәхетен тапкан кеше генә сөенә ала. Сергей үзен нәкъ шундыйлар рәтендә дип саный. Аңа 30 яшь тә юк әле. Шулай булуга да карамастан, тормышта күп нәрсәгә ирешә инде ул. Белгечлеге бар, көн саен чын күңеленнән яраткан эшен башкара—ул мастер Анатолий Трубкин җитәкчелегендәге скважиналарга җир асты ремонты үткәрү цехында өлкән оператор. 1983 елда «Норлатнефть» НГДУсына эшкә килгән егет башта бирегә оператор итеп алынган иде. Егет нефтьче хезмәтенең бөтен авырлыкларын өйрәнеп, аны яхшы итеп үзләштерде, үз эшенең чын остасына әверелде. Читтән торып Лениногорск нефть техникумын тәмамлавы да аңа үз һөнәренең бөтен нечкәлекләрен яхшы итеп өйрәнүгә ярдәм итте.

Өлкән операторның эше җаваплы. Тулаем вахта, анда эшләүчеләр, хезмәт нәтиҗәләре өчен җаваплылык аның өстендә. Аның белән бергә эшләүчеләрнең әйтүенә караганда, Сергей үз бурычын һәрчак намус белән үти. Ул таләпчән, коллективта ныклы дисциплина булдыруны беренче чираттагы бурычы итеп саный. Шуңа да ул җитәкләгән вахта үз планын даими үти. Шуңа өлкән операторның абруе да үскәннән-үсә бара. 1988 елда, мәсәлән, С. Власовның фоторәсеме «Татнефть» берләшмәсе Почет тактасына куелган иде.

Рәсемдә: НГДУның өлкән операторы С. Власов.

## УЧАСТОК ОЕШТЫРЫЛДЫ

22 гыйнварда МСОның отделка эшләре работниклары җыелышы булып үтте. Анда төзүчеләрнең бердәм фикере нигезендә отделка эшләре буенча төзелеш участогы оештырырга карар бирелде. Участок начальнигы итеп Х. Х. Хәбибуллин сайланды.

### Х. Х. Хәбибуллин

Хәким Хафизович Хәбибуллин 1957 елда Октябрь районының Савин авылында туган. Милләте буенча татар, махсус урта белемле, партиясез.

Хәким Хафизович 1974 елда, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан төзелеш техникумына укырга керә. 1975—1977 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Техникумны тәмамлаганнан соң ул 547 нче ПМКда мастер, прораб һәм өлкән прораб булып эшли. 1988 елның ноябреннән шушы ук ПМКда баш инженер вазифасын башкара.

## Халык депутатларының РСФСР, Татарстан АССР һәм Октябрь районының җирле Советларына халык депутатларын сайлау буенча участок сайлау комиссияләре председательләре, урынбасарлары һәм секретарьлары исемлеге

**2299, 1889, 2165, 1 нче**
**Яңа Иглай сайлау участогы**

Низаметдинов Хәмит Харисович— сайлау комиссиясе председателе.

Бикинеев Илдар Сәлимҗанович —председатель урынбасары.

Сатдарова Роза Фатыйховна —секретаре.

**2300, 1890, 2166, 2 нче**
**Ключи сайлау участогы**

Фәйзуллин Хәниф Сөләйманович —сайлау комиссиясе председателе.

Бикиев Хәлил Җәмилович — председатель урынбасары.

Алексеева Тамара Николаевна —секретаре.

**2301, 1891, 2167, 3 нче**
**Югары Норлат сайлау участогы**

Шәйхетдинов Рәис Хәмзиевич —сайлау комиссиясе председателе.

Фәхретдинов Сәлим Шакирович —председатель урынбасары.

Әһлиуллин Ранас Шакирович —секретаре.

**2302, 1892, 2168, 4 нче**
**Түбән Норлат сайлау участогы**

Вәлиева Мәйсәрә Минһаҗетдиновна —сайлау комиссиясе председателе.

Хәлитов Вәлияр Салихович — председатель урынбасары.

Ишмөхәммәтова Бибинур Шәрифулловна —секретаре.

**2303, 1893, 2169, 5 нче**
**Кормыш сайлау участогы**

Ибраһимов Якуб Таһирович —сайлау комиссиясе председателе.

## Планнар уңышлы үтәлде

Норлат халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе еллык планнарын уңышлы үтәде. Модалар ательесы да халыкка биргән вәгъдәсенә тугрылыклы булып калды. А. А. Дмитриева һәм Н. Я. Глухова җитәкчелегендәге бригадалар кабул итеп алынган планнарны 108,8—100,6 процентка үтәделәр. Ясалма чәчәкләр әзерләүче һәм венок үрүче Н. С. Цыганова, В. П. Абрамова, Е. П. Саймукова, К. Ф. Анорьева да эштә өлгерлек күрсәтәләр.

Район буенча исә Андреевка халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү пунктының эше мактауга лаек. Биредә ТАССРның атказанган көнкүреш работнигы Людмила Васильевна Сергеева эшли. Андреевка көнкүреш хезмәте күрсәтү пункты бер кешегә 55 сумлык хезмәт күрсәткән. Бу уртача алганда район буенча бер кешегә күрсәтелгән хезмәттән ике мәртәбә артыграк.

Л. МАРКОВА,
план бүлеге начальнигы.

## Максатлары зурдан

Норлат разведка бораулавы идарәсе бригадалары арасында сештырылган ярыш киң колач алды. Бүгенге көндә биредә удар хезмәт вахтасына басып эшләүчеләр шактый.

Ю. Н. Васюков җитәкчелегендәге вахта күркәм уңышларга ирешә. Узган елны вахта бораулаучылары 5 мең 625 метрда җир катламы тишәргә тиеш булсалар, фактта 6 мең 91 метр тирәнлектә бораулау эшләре үткәрделәр. Мастер Я. Г. Минхәеров вахтасы да сынатмый эшләде. Бу бораулаучылар уртак көч һәм бердәм хезмәт куюлары нәтиҗәсендә, җир катламын 6 мең 240 метрда тиштеләр, ягъни планны 111 процентка үтәделәр. Ф. И. Казаков вахтасы да мактаулылардан санала. План нигезендә ул 5 мең 505 метрда җир катламы тишәргә тиеш булса, чынбарлыкта 6 мең 489 метрда эш башкарды.

Алдынгы нефтьчеләр яңа елда яңа җиңүләр яулау һәм тагын да югарырак үрләргә менү максаты белән янып эшлиләр.

А. МАЛЫГИНА,
план бүлеге начальнигы.

